**<u>“Өмет”гәзите (Өфө шәһәре),  12 март 2016 ел</u>**

# Исәпленең малы төгәл

**Яки авыл хуҗалыгы исәбен алу ник кирәк?**

***2016 нчы — истәлекле елларның берсе булып истә калыр, мөгаен. Кәбисә елы булган өчен генә түгел, быел безнең һәркайсыбызны мөһим сәяси вакыйгалар көтә. Көз мәлендә шәһәр округларына, район муниципалитетлары һәм Дәүләт Думасына депутат сайлаулары үтәчәк. Моннан тыш, 2016 елның 1 июленнән 15 августына кадәр Бөтенрусия авыл хуҗалыгы исәбен алу кампаниясе үтәчәк. Бу чарада авыл хуҗалыгы җитештерүенең бөтен формалары да катнашачак. Бүген без БР Дәүләт Җыелышы– Корылтайның аграр мәсьәләләр һәм табигатьтән файдалану комитеты рәисе Рәсүл Үзбәк улы Госманов белән чираттагы әңгәмәбезне алда торган шушы мөһим вакыйгага багышладык.***

— Рәсүл Үзбәкович, сөйләшүне авыл хуҗалыгы исәбе алуның тарихыннан башлыйк әле?

— Авыл хуҗалыгы исәбен алуның яңа тарихы зур түгел. Моңа кадәргесе 2006 елда үткән иде. Әйткәндәй, мин дә ул чакта авыл хуҗалыгы исәбен алуда катнашкан идем. Аның ачык үтүе хәтеремә сеңеп калды. Үзгәртеп кору чорыннан соң ул кампания нинди дер яңалык булып килеп керде. Ни өчен? БМО-ның ФАО азык-төлек оешмасы дөнья илләренең ун елга бер тапкыр авыл хуҗалыгы исәбен алып барырга тиешлеге турында карар кабул итә. Бу чара — һәр илнең стандарт бурычлары. Күп илләрдә, мәсәлән, Европада, Америка илләрендә авыл хуҗалыгын исәпкә алу ешрак үтә. Алга киткән илләрдә биш-алты елга бер тапкыр үтсә, кайберәүләрендә — дүрт елга бер тапкыр. Ел саен үткәргән илләр дә бар. Бик чыгымлы һәм катлаулы булуына карамастан, ул бик файдалы һәм кирәкле эш.

—Аныклап әйткәндә, авыл хуҗалыгы исәбен алу ни өчен кирәк?

—Дөньядагы һәр ил үзенең иң мөһим ике иминлеген кайгырта. Аның беренчесе оборона иминлеге булса, икенчесе — азык-төлек иминлеге. Болар илнең көчле дә, йомшак та яклары. Безнең ил өчен азык-төлек иминлеге аеруча мөһим. Чөнки илнең күп төбәкләре катлаулы климат зонасында урнашкан. Бу кырыс һава шартларының авыл хуҗалыгы алып бару өчен катлаулы булуы турында сөйли.

Авыл хуҗалыгы — ул азык-төлек, туклану продуктлары, сәнәгать тармагы өчен чимал чыганагы. Ягъни илебез икътисады теге яки бу дәрәҗәдә авыл хуҗалыгы җитештерүенә бәйле. Дәүләтебез авыл хуҗалыгы сәясәтен илебез иминлеген тәэмин итәрлек итеп алып бара. Моның өчен алдан күрә белүчәнлек, планлаштыруның югары дәрәҗәсе булырга тиеш. Боларның барысы бергә таяныр өчен мөһим фактик материаллар кирәклеге турында сөйли. Беренчедән, дәүләт органнары, икенчедән җәмәгать оешмалары тарафыннан. Бөтен нормалар, шул ук исәптә закон нормаларын, статистик яки отчет мәгълүматларын да кертеп, Русия һәм БР бюджеты билгеләнә. Моннан тыш, хөкүмәттә фактик мәгълүматларга таянучы социаль-икътисади үсеш фаразлары да бар. Без һәр елны социаль-икътисади үсеш прогнозына, бюджетка төзәтмәләр кабул итәбез. Әлбәттә, без Башстат яки Росстатка да таянабыз. Әмма статистика заманча хуҗалык итүнең бүгенге бөтен формаларын да үз эченә алып бетерми. Хәзер, беренчедән, шәхси ярдәмче хуҗалыклар күбәя. Тупас исәп белән әйткәндә, аларның саны 500 меңнән артып китә. Икенчедән, крестьян-фермер хуҗалыклары. Өченчедән, авыл хуҗалыгы предприятиеләре

— болары иң ерелəреннəн санала. Алар арасында тагын да эрерəклəрен — агрохолдингларны да күрəсебез килə.

Əгəр статистика авыл хуҗалыгы предприятиелəрен яхшы яктыртса, крестьян-фермер хуҗалыклары, бигрəк тə шəхси-ярдəмче хуҗалыклар тиешле дəрəҗəдə саналмаган. Соңгы ун елда җитди үзгəрешлəр булды, аларны, һич шиксез, белү мөһим. Шəхсəн, минем өчен бу вакыт эчендə авыл хуҗалыгында нинди үзгəрешлəр булуын статистика дəрəҗəсендə төгəл белү кызыклы булачак. Шəхси ихаталарда мал башы, сөт савып алу, шул исəптəн, алар кичергəн авырлыклар да кызыклы булачак.

— Авылда яшəүчелəр өчен исəп алу əһəмияте моның белəн генə бетмидер, мөгаен?

— Сез хаклы. Моннан тыш, “Өмет”не укучылар өчен тагын берничə функцияне аерып əйтəсем килə. Беренчедəн, ул авыл хуҗалыгы исəбен алуның оештыру һəм агитация функциялəре. Авыл хуҗалыгында шөгыльлəнүче һəр кеше ниндидер ориентирларга таяна. Ул ориентирлар конкрет кешегə, шəхси ихата хуҗасына, аның гаилəсенə нəтиҗəлəр ясау мөмкинлеген бирə. Əйтик, ун ел элек малым шулкадəр иде, быел исə шулкадəр дип. Ягъни шəхси нəтиҗəлəр ясау мөмкинлеге. Алга карап планнар төзү өчен дə кирəк ул.

Безнең илдə авыл хуҗалыгы исəбен алу тарихының җитди таянычы юк. Мин авыл хуҗалыгы исəбен ешрак алып бару яклы. Ник дигəндə, беренчедəн, без катгый икътисади санкциялəр шартларында яшибез. Бүген импортны алмаштыру процессы бара, ягъни базарларда чит ил продукциялəре үзебезнең илдə җитештерелгəннəре белəн алмаштырыла. Хəзер авыл хуҗалыгы белəн шөгыльлəнергə зур мөмкинлеклəр ачылды. Бүген аграр икътисадта пəйда булучы тəүге яшел шытымнар — алар авылда искə алынырга тиеш булган эшкуарлыкның башы.

Авыл кешелəрен генетик яктан ныклы, чын хезмəтчəннəр дип исəплим мин. Авылда яшəргə һəм эшлəргə телəмəүчелəр аннан күптəн китте. Авылны чынлап сөйгəн кешелəр генə торып калды анда. Бүген авылда яшəве дə җиңеллəште. Социаль шартлар тудырыла, зəңгəр ягулык керə, таш юллар түшəлə. Телəгəн кеше үз эшен ача, эшкуарлык белəн шөгыльлəнə ала. Моның өчен уңай шартлар тудырыла. Авыл хуҗалыкларына һəм аграр предприятиелəргə ярдəм күрсəтелə. Аларга тагын да киңрəк ярдəм итүне күзаллау өчен дə кирəк исəпкə алу кампаниясе.

— Рəсүл Үзбəкович, авыл хуҗалыгы исəбен алу шактый чыгымнар талəп итə. Никадəр дəрəҗəдə үзен аклый ул? Бигрəк тə бүгенге катлаулы вакытта.

— Кабатлап əйтəм, беренчедəн, авыл хуҗалыгы исəбен алу — һəр илнең бурычы ул. Икенчедəн, югарыда əйткəнемчə, төгəл планлаштыру өчен кирəк. Кайчак кайбер авыл хуҗалыгы предприятиелəре буенча мəгълүматлар арттырып күрсəтелə дигəн шик бар. Болар минем сүзлəр түгел. Ил һəм республика җитəкчелеге сүзлəре. Саннарда аерма булуы мөмкин. Ни өчен? Дəүлəт статистика комитеты белəн төрле союзлар, ассоциациялəр һəм башка ведомстволар арасындагы саннар төрлечə. Шуңа да Бөтенрусия авыл хуҗалыгы исəбен алу бу бəхəстə зур нокта куярга тиеш. Ул безгə билгеле дəрəҗəдə авыл хуҗалыгындагы хəллəрне ачачак.

— Авыл хуҗалыгы исəбен алу ничек үтəчəк?

— Əлбəттə, аның өчен закон нигез булып тора. Ул “2016 елдагы Бөтенрусия авыл хуҗалыгы исəбен əзерлəү һəм үткəрү буенча БР район муниципалитетлары һəм шəһəр округларының урындагы үзидарə органнарын дəүлəт вəкалəтлəре белəн бүлү” турындагы законга ярашлы үткəрелə. Ул — БР Дəүлəт Җыелышы тарафыннан быел кабул ителгəн яңа закон. Шуңа ярашлы, авыл хуҗалыгы исəбен алуга əзерлек эшлəре актив бара. Исəп алу, һичшиксез, чыгымнар талəп итə. Кешелəрне укытырга, аларны экипировка, бина,

транспорт, басма материаллар белән тәэмин итәргә кирәк. Аларның барысы турында да законда әйтелә. Урыннардагы власть органнары бу җәһәттән ел ахырына кадәр җиң сызганып вәкаләтләрен башкарырга әзер булырга тиешләр.

Моннан тыш, авыл хуҗалыгы исәбен алучылар — алар без һәр көнне күргән-күрешкән кешеләр. Алар муниципаль берәмлек хезмәткәрләре дә, Башкортсан статистика хезмәткәрләре дә булырга мөмкин. Мәгълүм булуынча, авыл хуҗалыгы исәбен алучылар анкета рәвешендә сораулар бирәчәк. Авыл хуҗалыгы исәбен алуда катнашу —ул гражданлык бурычы. Соңыннан аның мәгълүматлары киң җәмәгатьчелек игътибарына җиткереләчәк. Алар һәркем өчен ачык булачак.

—Рәсүл Үзбәкович, мәгълүматларны салым салу өчен җыялар икән дигән имеш-мимешләр дә юк түгел...

—Асылда, безнең илдәге салымнар дөньяда иң түбәннәрдән санала. АКШ һәм Европаның кайбер билгеле шәхесләре бәлки шуңа да безнең илгә омтыла башлагандыр. Безнең илнең салым сәясәте гражданнарны бик саклый. Сезнең сорауга килгәндә исә, авыл хуҗалыгы предприятиеләренә һәм авылда яшәүчеләргә һәм эшкуарлыгын үстерергә теләгән кешеләргә карата ярдәм күрсәтү стратегиясе әзерләнә. 2015 ел ахырында гына илебез президенты В.В. Путин "Бердәм Русия" партиясе съездында авыл хуҗалыгы тәгаенләнешендәге сорауларны күтәрде. Шуларның берсе — эшкәртелми яткан җирләр турында. Бүген яшь агачлар, чүп үләннәре каплап алган чәчүлекләрнең тик ятуы беркемгә дә сер түгел. Авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен ул җирләрнең әһәмияте югалмаган әле. Статистика әнә шундый файдаланылмый яткан (ташландык түгел!) җирләрне исәпкә алачак. Моннан тыш, безнең халык арасында хокукый наданлык дигән нәрсә дә бар. Ягъни алар үзләренең милки хокукларын, колхозлардагы җир өлешләрен, милек һәм җир пайларын гамәлгә ашыру хокукларын белмиләр. Соңгы дистә елларда эшләгән предприятиеләрне саклап калу да мөһим. Зур авыл хуҗалыгыннан башка авылда яшәү мөмкин түгел. Бу коллективка, кооперативка тупланып яшәргә кирәк дигәнне аңлата. Бөтенрусия авыл хуҗалыгы исәбен алу кампаниясе әнә шуңа багышланачак та инде. Кабатлап әйтәм, ул салым оешмалары өчен коры мәгълүмат җыюга гына кайтып калмый. Салым органнары, кирәк булса, мәгълүматларны башка чыганаклардан да ала алалар. Авыл хуҗалыгы исәбен алу — ул авыл хуҗалыгы статистикасы буенча алынган мәгълүматларны ачыклауга юнәлтелгән һәм моннан тыш авылда яшәүчеләрнең үзләре өчен ориентир чыганагы булып торырга тиеш. Алар үзләре өчен нәтиҗәләр ясарга тиеш. Бу иң мөһиме!

— Бүген һәр авылда, кем әйтмешли, дачниклар бар. Аларны да санаячаклармы?

— Күпләр авыллардагы бөтен дачникларны да кертеп санаячаклар дип уйлый. Асылда, барлык дачниклар да исәпкә алынмаячак. Күпләр үзләренең дачаларында үлән генә үстерә. Быел исә күпләр кош-корт асрарга, бәрәңге, яшелчә утыртырга кирәк, ди. Аннары, үзең чәчеп үстергән тәмлерәк тә, файдалырак та шул.

Дөньяның бер илендә дә бездәгедәй дачалар тотып, анда яшелчә-җимеш үстерүчеләр юк. Бакча участоклары белән яшәүчеләр юк диюем. Мәсәлән, заманында ГДР-да булган, хәзер алар анда да бетте. Чөнки анда законнар катгый, шәхси ихатада бакчаны карап тоту да артык кыйммәткә төшә. Җирләрне кире дәүләткә кайтардылар. Безнең илдә исә дачада эшләү өчен мөмкинлекләр бар.

Ә менә шәхси ихатаңда рәхәтләнеп мал асыра, бакча үстер! Шәхси ихатадагы мал кешене ит һәм сөткә генә туендырмый, эш белән дә тәэмин итә. Бу бик яхшы. Кеше саф һавада эшли, гаиләсен дә туендыра. Моннан тыш Авыл хуҗалыгы министрлыгы шәхси

ихатаны үстерүгә бүленгән кредитларны да компенсацияләргә булыша. Ягъни кредитның процент ставкасы компенсацияләнә. Бу да җитди ярдәм. Хәзер менә яз башланды. Авылда эш башларгамы-юкмы дип аптыраштa калучылар да юк түгел. Эшкуармы ул, шәхси хуҗалыгын алып барырга теләүче булсынмы, әгәр ул миннән авылга кайтыргамы-юкмы дип сораса, мин һәрвакыт “кайтырга кирәк” димен. Авыл хуҗалыгы исәбен алганда без бу хәлләрнең дә чын күренешен күрәчәкбез.

Югарыда әйткәнемчә, исәпне алу — статистика хаталарын түгел, ә хәл-вакыйгаларның чынбарлыгын ачыклау. Аермалыклар җир белән күк арасы кадәр булыр дип уйламыйм. Кайдадыр искә алынмаган нәрсәләр табылса, кайбер урында җитештерү буенча артыклыклар да табылыр, мөгаен. Бигрәк тә шәхси ихаталарда моңарчы исәпкә алынмаган нәрсәләр табылыр. Авыл хуҗалыгы исәбен алу, һичшиксез, файдалы нәтиҗәләр генә бирәчәк.

Шәһәр кешесе авыл хуҗалыгын кибеттә генә тоя бит. Алар авыл хуҗалыгы җитештерүендә катнашмый, авылда үстерелгән малларны да күрми. Кала кешесе суыткычы белән тавыш бирә, дигән гыйбарә бар. Авыл хуҗалыкларындагы хәлләр торышын белү кала халкына да файдалы булачак.

Без аграр республикада яшибез, барыбыз да теге яки бу дәрәҗәдә авыл белән бәйлебез. Күпләребезнең тамырлары авылдан. Кабатлап әйтәсем килә: авыл хуҗалыгы исәбен алу авыл халкына ниндидер салымнар салу, аларның хокукларын кысрыклау өчен түгел, киресенчә, аларга төпле ярдәм бүлүгә дә юнәлтелгән. Авыл хуҗалыгы исәбен алу ачык, аңлаешлы һәм барыбыз өчен дә шатлыклы бәйрәм төсендә үтәргә тиеш.

**Резеда Кадикова.**